РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18 ноябрь 2020 ел** **№ 12**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Бишалаб авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Бишалаб торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2020 елнын 30 нче ноябренэ 11.00 сэгатькэ билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Бишалаб торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2021 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

Бишалаб авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
1) Бишалаб т. п. да Үзәк урамы буенча юл-урам челтәрен төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

2) Бишалаб т. п. юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Бишалаб т.п. территориясен чуп улэннэреннэн чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).
4) Бишалаб т. п. да янгын гидрантларын тэртиптэ тоту (янгын гидрантларын, краннарны (җайланмаларны) кышка җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек һәм тикшерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

« ӘЙЕ»        «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________И.Х.Сәгдиев